
# Сокланырлык гомер юллары

Башка җирләр миңа кирәк түгел,

Туган ягым,миңа  син кирәк



Биш  кыз туган - Нәбиуллиналар.


Воинское

Куда

Кому

Адрес отправителя:

ПОЛЕВАЯ ПОЧТА

(указать № полевой почты)

(фамилия, имя и отчество)

Бьем немца пулей и снарядом,
Громим в атаке штыковой!
Не быть земле под немцем гадом,
Быть немцу гаду под землей!

Выше черты не писать

Кәрибулла абыйның соңгы хаты.



Сулдан икенче утырган- Зәйтүнә апа.

# Яшәү кадерен белеп

Һәр бирмеш көннең тәмен белеп, кадерләп, зурлап яшәүчеләр бар. Олы Салтык авылында гомер кичерүче 81 яшьлек Зәйнәп әби Ибәтова нәкъ шундый кешеләрнең берсе. Бу гаҗәп тә түгел– чөнки әби сугыш чоры балаларының берсе. Михнәт күрмәгән, рәхәтнең дә кадерен белми диләр, ул елларда хатын- кызлар үсмерләр, балалар күргән нужаны бүген кем генә аңлар?! Юк, аңламас, чөнки нужаны нужа күргән генә белә. Шуңа күрә дә Зәйнәп әби булганына шөкер итеп, барысыннан канәгать булып, матур картлык кичерә. 6 балалы зур һәм хезмәт сөючәнлекләре белән танылган, алдынгы карашлы, укымышлы Гарифулла абзый белән Миңнебикә апа гаиләсендә үсә ул. 7 яшендә Олы Салтык җиде еллык мәктәбенә укырга керә. Сыйныфташлары арасында кызыксынучан, зиһенле, тырыш укучы буларак аерылып тора. Хыялы– урта белем алып, табибә булу.

Ләкин язмыш үзенчә хәл итә. 1941 елда, кыз җидееллык мәктәпне тәмамлагач, Ватан сугышы башлана.

"Әле дә хәтеремдә, яңгырлы көн иде. Сугыш башлану турындагы хәбәрне ишетеп,

та кортыдай гөжләде– елашалар, аптырап калган халык бергә җыйнаулашып алда ниләр булыр, нәрсәләр көтә дип кайгыра. Ир- атлар гына, үзләренә хас булган ныклык белән сабырлык сакларга тырышып, "кайгырмагыз, озакка бармас", дип аларны юатырга тырыша. Ул чагында берәү дә сугышның озын- озак елларга сузылачагын, үз артыннан миллионлаган корбаннар калдырып тарихта иң дәһшәтле һәм газаплы чор булып калачагы турында башына да китермәгәндер. Икенче көнне күп ир- атлар саубуллашып, исән булсак бер кайтырбыз, дип фронтка китеп баралар.

Бер атнадан Гарифулла абыйлар гаиләсе дә уллары Кәрибулланы канлы сугышка озата, (әтиләре карт булу сәбәпле алынмый) шул ук елны хатын- кызларны окоп казу эшләренә җәлеп итәләр. Әниләренең күкрәк баласы булу сәбәпле, Зәйнәп бер иптәш кызы белән аның урынына Апас ягына окоп казу эшенә китә. Әле сабыйлыктан да чыгып җитмәгән кызларны күргәч, прораб: "Монда балалар бакчасы түгел, хәзер үк кайтып китегез, әниләрегез килсен", дип ачулана. Елап, ялварып хәлне аңлаткач, калырга



белән бергә ул елгы салкында халыкның үзәгенә үтә. "Сугыш елларында ат та булдык, машина да булдык",– ди Зәйнәп әби хатирәләргә бирелеп– укулар ул вакытта (Олы Карамал мәктәбенә йөреп укый) көзге эшләр беткәч– октябрьдә башлана иде, ял көннәре, каникулда да колхозда эшләдек". Әнә шулай яшүсмерләр карт- коры белән бергә печәнен дә чаба, урагын да ура, көлтә бәйли, кул арбасы белән

лык сугу– җилгәрү кебек эшләрдә дә катнаша. "Көзен урак урганда көн саен яңгыр явып үзәккә үтә иде. Яңгыр ява- ява күшеккәнче эшлибез, аяклар шешенә– инде түзәр әмәл калмагач– өйгә кайтабыз гына– кояш чыга. Янәдән кырга китәбез". Шунысын да билгеләп үтми мөмкин түгел, Зәйнәп районда иң алдынгы уракчы була, моны туган якны өйрәнү музеендагы язмаларда раслый.

Авылга кара пичәтле хатлар килеп тора. 1943 елда кайгы Зәйнәпләр ишеген дә кага– бердәнбер ир туганнары Кәрибулла Сталинград янындагы бәрелештә һәлак була.

көнне өй юа идек. Моңсу карашлы, уңайсызланып кына ишек каккан хат ташучыларны күргәч, йөрәкләр аерылып киткәндәй булды,– кулдан эш төште, әни елый, без елыйбыз, күршеләр керде. Шулай да күңелнең бер почмагында "бәлки исәндер" дигән уй ташламады. Әни күрәзәче багучыларга да йөрде, "исән, кайтыр" дип өметләндерделәр. Хәсрәтле ана йөрәген тагын да яраламас, өмет белән яшәтер өчен ак ялганга барганнардыр инде. Еллар арты еллар килде, ә ул кайтмады..."

Җиңү хәбәрен мәктәптә ишетәләр. Кемдер елый, кайсыдыр шатланып кычкыра. Радиодан Левитанның көр тавышы сугыш бетүен игълан итә, халкыбызны бөек җиңү белән котлый. Барысы бердәм булып демонстрациягә чыгалар. Үзем Зәйнәп әби сөйләгәннәрне тыйлыйм, үзем уйланам, бу бер аның язмышы гына түгел, ил язмышы, миллионнар кичкән сынаулар бит бу. Ә менә табибә булу теләге генә хыял булып кала. Укытучы, райпо системасына да эшкә чакыралар– тик Гарифулла абзый кызын читкә

җирдә, кызым, бәхетеңне туган җиреңдә табарсың, әтиеңсүзенә каршы килмә, ди. Һәм ул ризалаша. 1948 елда авыл егете Хәмидулла белән гаилә коралар. Өйләнешкәннән соң тормыш иптәше өч ел ярым армия хезмәтендә булып кайта. Бер- бер артлы дүрт балалары туа. Балалары тәүфыйклы булып үсәләр. Әниләренә карата игътибарлы һәм миһербанлылар. Кайсына барса да урыны түрдә, кадерләп кенә йөртәләр. Инде оныкларны гына түгел, оныкчыкларны сөеп шатлана. "Тормышлар әйбәт, без генә картайдык",–ди ул. Яшьләргә дә әйтер сүзе бар. "Хәзерге яшьләрнең бозылуына бик борчылам. Җәннәт кебек тормыштан риза түгелләр, хезмәт ит, эшләсәң– бар да була, акчасын түлиләр. Без таякка эшләдек, пенсиябез дә кечкенә булды– зарланмыйбыз, биргәненә шөкер итәбез. Иң мөһиме күгебез аяз, ашыйм– киям дисәң– җаның ни тели– шул бар. Бүгенге тыныч тормышның кадерен белеп яшәсеннәр иде, ди.

Әйе, Зәйнәп әби хаклы. Ходай биргән гомернең өлкән буыннар кебек матур эшләр белән генә бизәп, ялгышмый, үкенмәслек итеп яшисе иде.

## Өченче кыз-Зәйнәп апа



Уңнан беренче утырган- Тәнзилә апа.



Әлфия апа балалар һәм оныклар белән



Гаиләдә икенче кыз-Разия апа



Тормыш иптәше Шәйхулла абый белән.

# РАЙОН ТОРМЫШЫ

гаилә елы

## Сокланырлык гомер юлы

РИММА НӘБИУЛЛИНА

**Күңелем белән авылымның һәр өендә булып чыктым. Ничек гомер итүләрен, күршекүлән белән нинди мөгамәләдә торуларын, тегә яки бу гаиләнең авылдашларым алдындагы дәрәҗәсен барладым һәм, 58 ел бергә яшәп,күптән түгел генә мәңгегә хушлашкан Шәйхулла абый белән Разия апа гаиләсенә тукталдым.**

1950 нче елның чалт аяз, зәмһәрир суыклы гыйнвар аенда сугыш кырларында җиңү яулап кайткан Шәйхулла абый белән авыл мөгаллимәсе Разия апа тормыш корып җибәрә. Гыйнвар ае салкын булса да, аның җемелдәгән ак карлары озын тормыш юлына бары тик сафлык, пакьлек өстәп торган намуслы, сабыр булырга булышкан, сокланкгыч гомер юлы сузган сыман. Әйе, дус һәм тату гаилә башлыгы Шәйхулла абый гомере буена намуслы хезмәт итә. Авылда (каядыр түгел) балта остасы булып танила. Аның кулы белән төзелгән йортлар, ул йортларга ясалган тәрәзә йөзлекләре, өй кыекларына уелган бизәкләр һәркемне сокландыра. Ул гына да түгел, авыл һәм район сәхнәләрендә улы, кызы, оныклары белән үзе ясаган кубызда уйнап чыгышлар ясый, матур итеп җырлый. Аның башкаруындагы "Башка мине күрә алмассың", "Сарманай", "Карагай" кебек җырлар авыл өстендә моңсу көй булып бик күп еллар яңгырар әле. "Кеше китә - җыры кала" дигән гыйбарә шулдыр инде ул, мөгаен.



Ә Разия апа мәктәптә 35 ел татар теле һәм әдәбияты укыта: шигъри җанлы, тормышка чын мәгънәсендә гашыйк укучылар тәрбияли. Ул бүген дә укучылары белән горурланып яши. Хәзерге көндә драматург Туфан абый Миңнуллин туган телебез сагында армый-талмый хезмәт итә икән, монда бит Разия апаның да өлеше бар.

Гаилә белән яшәү, эш белән генә яшәү түгел бит әле. Тормыш шатлык - куанычларсыз да, шул ук вакытта мәшәкатьсез дә булмый. Менә шулар арасында югалып калмыйча, гаилә җылысын саклап кала алу – монысы инде һәркемнең кулыннан килмидер, мөгаен. Ул бит җәмгыять кануннарыннан да, әлбәттә, кешенең үзеннән дә тора. Менә шул җәһәттән мин Разия апага (мин аңа "апа" дип мөрәҗәгать иттем, чөнки укытучыга без хөрмәт итеп гомере буе "апа" дип эндәшәбез) сорау бирдем.

**– Разия апа, сез балалар үстергән 50-60 нче елларда хөкүмәт тарафыннан бала тәрбияләүгә, гомумән, гаиләгә караш нинди иде?**

– Ул елларда авыл җирләрендә балалар бакчасы юк. Ә безгә, укытучыларга, нишләргә кала? Җитмәсә декрет ялы да бик аз, ничәдер көн генә бирелә. Өеңдә караучы кешең булмаса, бер айлык балаңны күршеңә кертеп калдырасың, тәнәфес яки буш сәгатьләрдә йөгерә-йөгерә кайтып (нindидер гаепле кеше сыман), балаңны ашатып киләсең. Дәресләр беткәч, һәркөнне җыелыш яки агитаторлык эше. Агитаторлык эшенә йомырка, май җыю да, тагын бик күп мәшәкатьләр кирә иде. Балаң өчен вакыт тәнгә кала. Ә бу йөкне гаиләң тату булмаса, берничек тә тартып бара алмас идең. Кызларымны чәч үрергә, киенә белергә нәкъ менә әтиләре өйрәтте. Ә бүгенге яшьләргә бала тәрбияләүдә, матур гаилә коруда мөмкинлекләр күп. Менә быелгы елның Гаилә елы дип игълан ителүе моның бик әһәмиятле икәнлеген күрсәтә.

Үткәннәрне искә төшергәндә Разия апага бик моңсу иде. Ләкин үкенечле түгел, үкенечле итеп яшәмәгәннәр бит алар: һәркөнне изгелек кылып, балаларына һәм оныкларына намус, сабырлык үрнәге булып, гаилә җылысын ни дәрәҗәдә сүндермичә саклап булуына ышанырлык итеп гомер иткән алар. Сокланырлык гомер юллары, сокланырлык гаилә менә шундый буладыр ул!

Пролетарии всех стран, соединяйтесь!



Под знаменем марксизма-ленинизма, под руководством Коммунистической партии-вперед, к победе коммунизма!

# Почетная
# ГРАМОТА

Камско-Устьинский РК КПСС и исполком райсовета депутатов трудящихся награждают настоящей грамотой

НАБИУЛЛИНУ РАЗИЮ НАБИУЛЛОВНУ

учительницу татарского языка и литературы Б.Салтыковской восьмилетней школы, за долголетнюю и плодотворную работу по воспитанию подрастающего поколения.

Секретарь РК КПСС:
/Х.Ахмадуллин./

Председатель исполкома райсовета:
/М.Драгунова./

25/VIII-1966г.




Разия апа һәрвакыт хөрмәткә лаек.

# Туфан Миңнуллин


*"Айгыртауның айлы җиле*
*Юата төн карасын.*
*Тауга карап , тау булалган*
*Туфан булып кара син! "*

*Марсель Галиев*

*Әйе, бүгенге драматургиянең иң якты йолдызларының берсе. Язучы - драматург,танылган җәмәгать эшлеклесе, 40тан артык пьеса авторы, РСФСР ның Станиславский, Татарстанның Г.Тукай , М.Җәлил исемендәге премияләре лауреаты.Татарстан Дәүләт Советы депутаты.*



*1965 елда иң беренче басылган китабы. Ул татар теле һәм әдәбияты укытучысы Разия Нәбиуллинада саклана.*










Әнисе юлын сайлаган кызы-Миләүшә апа.

Без биш бала үстек әнкәй белән,
Тик үсмәдек иркә кочакта.
Без әнкәйнең биш шатлыгы идек
Биш кайгысы булдык кайчакта.

Башка җирләр миңа кирәк түгел,
Туган ягым миңа син кирәк.
Биш кыз туган – Нәбиуллиналар.



# Разия апа һәрвакыт хөрмәткә лаек.











# РАЙОН ТОРМЫШЫ

гаилә елы

## Сокланырлык гомер юлы

РИММА НӘБИУЛЛИНА

**Күңелем белән авылымның һәр өендә булып чыктым. Ничек гомер итүләрен, күршекүлән белән нинди мөгамәләдә торуларын, тегә яки бу гаиләнең авылдашларым алдындагы дәрәҗәсен барладым һәм, 58 ел бергә яшәп,күптән түгел генә мәңгегә хушлашкан Шәйхулла абый белән Разия апа гаиләсенә тукталдым.**

1950 нче елның чалт аяз, зәмһәрир суыклы гыйнвар аенда сугыш кырларында җиңү яулап кайткан Шәйхулла абый белән авыл мөгаллимәсе Разия апа тормыш корып җибәрә. Гыйнвар ае салкын булса да, аның җемелдәгән ак карлары озын тормыш юлына бары тик сафлык, пакьлек өстәп торган намуслы, сабыр булырга булышкан, сокландыргыч гомер юлы сузган сыман. Әйе, дус һәм тату гаилә башлыгы Шәйхулла абый гомере буена намуслы хезмәт итә. Авылда (каядыр түгел) балта остасы булып танула. Аның кулы белән төзелгән йортлар, ул йортларга ясалган тәрәзә йөзлекләре, өй кыекларына уелган бизәкләр һәркемне сокландыра. Ул гына да түгел, авыл һәм район сәхнәләрендә улы, кызы, оныклары белән үзе ясаган кубызда уйнап чыгышлар ясый, матур итеп җырлый. Аның башкаруындагы "Башка мине күрә алмассың", "Сарманай", "Карагай" кебек җырлар авыл өстендә моңсу көй булып бик күп еллар яңгырар әле. "Кеше китә - җыры кала" дигән гыйбарә шулдыр инде ул, мөгаен.



Ә Разия апа мәктәптә 35 ел татар теле һәм әдәбияты укыта: шигъри җанлы, тормышка чын мәгънәсендә гашыйк укучылар тәрбияли. Ул бүген дә укучылары белән горурланып яши. Хәзерге көндә драматург Туфан абый Миңнуллин туган телебез сагында армый-талмый хезмәт итә икән, монда бит Разия апаның да өлеше бар. Гаилә белән яшәү, эш белән генә яшәү түгел бит әле. Тормыш шатлык - куанычларсыз да, шул ук вакытта мәшәкатьсез дә булмый. Менә шулар арасында югалып калмыйча, гаилә җылысын саклап кала алу – монысы инде һәркемнең кулыннан килмидер, мөгаен. Ул бит җәмгыять кануннарыннан да, әлбәттә, кешенең үзеннән дә тора. Менә шул җәһәттән мин Разия апага (мин аңа "апа" дип мөрәҗәгать иттем, чөнки укытучыга без хөрмәт итеп гомере буе "апа" дип эндәшәбез) сорау бирдем.

**– Разия апа, сез балалар үстергән 50-60 нче елларда хөкүмәт тарафыннан бала тәрбияләүгә, гомумән, гаиләгә караш нинди иде?**

– Ул елларда авыл җирләрендә балалар бакчасы юк. Ә безгә, укытучыларга, нишләргә кала? Җитмәсә декрет ялы да бик аз, ничәдер көн генә бирелә. Өеңдә караучы кешең булмаса, бер айлык балаңны күршеңә кертеп калдырасың, тәнәфес яки буш сәгатьләрдә йөгерә-йөгерә кайтып (ниндидер гаепле кеше сыман), балаңны ашатып киләсең. Дәресләр беткәч, һәркөнне җыелыш яки агитаторлык эше. Агитаторлык эшенә йомырка, май җыю да, тагын бик күп мәшәкатьләр кирә иде. Балаң өчен вакыт төнгә кала. Ә бу йөкне гаиләң тату булмаса, берничек тә тартып бара алмас идең. Кызларымны чәч үрергә, киенә белергә нәкъ менә әтиләре өйрәтте.

Ә бүгенге яшьләргә бала тәрбияләүдә, матур гаилә коруда мөмкинлекләр күп. Менә быелгы елның Гаилә елы дип игълан ителүе моның бик әһәмиятле икәнлеген күрсәтә.

Үткәннәрне искә төшергәндә Разия апага бик моңсу иде. Ләкин үкенечле түгел, үкенечле итеп яшәмәгәннәр бит алар: һәркөнне изгелек кылып, балаларына һәм оныкларына намус, сабырлык үрнәге булып, гаилә җылысын ни дәрәҗәдә сүндермичә саклап булуына ышанырлык итеп гомер иткән алар. Сокланырлык гомер юллары, сокланырлык гаилә менә шундый буладыр ул!

---

Пролетарии всех стран, соединяйтесь!



Под знаменем марксизма-ленинизма, под руководством Коммунистической партии – вперед, к победе коммунизма!

# Почетная ГРАМОТА

Камско-Устьинский РК КПСС и исполком райсовета депутатов трудящихся награждают настоящей грамотой

НАБИУЛЛИНУ РАЗИЮ НАБИУЛЛОВНУ

учительницу татарского языка и литературы Б.Салтыковской восьмилетней школы, за долголетнюю и плодотворную работу по воспитанию подрастающего поколения.

Секретарь РК КПСС: /Х.Ахмадуллин./

Председатель исполкома райсовета: /М.Драгунова./

25/VIII-1966г.